КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 март г.Казань № 343

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 февраль, 76 нчы карары белән расланган Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 февраль, 76 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 июль, 710 нчы; 2022 ел, 15 декабрь, 1336 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибенә, 2.3 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин